СОВЕТ
ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРӘ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2026 г.Мензелинск № 1

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Советының 11.03.2014 елның 3-1 номерлы «ТР Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 16.12.2019 елгы 431-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.2021 елгы 14-П номерлы Карарының резолютив өлешенең 1 пунктының 2 абзацы, 14.07.2022 елгы Федераль законның 3 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасы нигезендә «Җир асты байлыклары турында" Россия Федерациясе законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына, "Биналар һәм корылмалар иминлеге турында техник регламент" Федераль законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 25.12.2023 ел, 653-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасының 5 абзацына үзгәрешләр кертү турында» 343-ФЗ нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 11.03.2014 ел, № 3-1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 2.53 пунктында «закон белән» сүзен «закон белән. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган төбендәге грунт калдыкларга керми.» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Кагыйдәләрнең 5 бүлегендәге 5.6.9 пунктының 14 пунктчасында "кунак" сүзеннән соң «тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларда стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итәргә;» сүзләрен өстәргә.;

1.3. Кагыйдәләрнең 2 бүлегендәге 2.53 пунктына «, шулай ук «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә кулланылырга тиешле ярылган һәм сыешлы тау токымнары" сүзләрен өстәргә.»;

1.4. Кагыйдәләрнең 2 бүлегендәге 2.37 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.37. инженер-техник тәэмин итү челтәре - электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су агызу челтәре, элемтә челтәре һәм бинаны һәм (яисә) корылманы инженер-техник тәэмин итү өчен билгеләнгән башка корылмалар, шулай ук мондый челтәрләр җыелмасы;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф.Сәлахов